**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“17” ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-Төрекләр авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту;

-Төрекләр авылы зиратын төзекләндерү өчен материаллар алу.

- Төрекләр авылына зират коймасы кору.

-Төрекләр авылын чистарту,төзекләндерү өчен чыгымнар тоту.

-Яшь Коч урамындагы күперне ремонтлау.

- җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Төрекләр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Төрекләр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.